Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 ноябрь, 2023 ел № 280

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2019 елның 25 июлендәге 210 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә (2019 елның 05 декабрендәге 235 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 27 номерлы, 2023 елның 12 апрелендәге 224 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Район Башкарма комитетының вәкаләтләре» 4 өлештә:

- 4.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«- әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыра һәм район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыра.»;

- 4.6 пунктының җиденче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглый һәм гамәлгә ашыра;».

1.2. «Район Башкарма комитеты җитәкчесе» 5 өлеш түбәндәге эчтәлекле 5.6 пункт өстәргә:

«5.6. Район Башкарма комитеты җитәкчесе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында

башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәгән, шулай ук мондый бурычларны үтәмәгән очракта аңа бәйле булмаган хәлләр нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3 - 6 өлешләрендә каралган тәртиптә ачыкланган өчен җаваплылыктан азат ителә.

1.3. 9 өлешнең 9.1 пунктында «Районның башкарма комитеты җитәкчесе башкарма комитетының вәкаләтләре вакытыннан алда туктат

- 13 пунктчаны төшереп калдырырга;

- 14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләрен башкаручы Район башлыгы вазыйфасына керешү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов